РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Урманаевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Татарстан д.15«А»,, Азнакаевский район,
с.Урманаево, 423311,
тел./факс (885592)43-0-49
E-mail: Urman.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге
башкарма комитеты

Татарстан ур., йорт 15 “А”, йорт, Азнакай
районы, Урманай авылы, 423311
тел./факс (885592)43-0-49
E-mail: Urman.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19 » октябрь 2022ел № 18

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 февралендагы 05/76 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урманай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты әзерләү хакында (31.03.2016 №07/28, 19.11.2016 №21/42, 04.09.2017 № 13/60, 11.07.2018 №18/102, 19.03.2019 №07/130, 19.02.2020 №02/158, 12.08.2021 № 16/36, 06.07.2022 № 23/71 номерлы карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга таянып, Урманай авыл җирлеге башкарма комитетының җирдән файдалану һәм төзелеш эшләре алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советы карар итә:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 февралендагы 05/76 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Урманай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (31.03.2016 №07/28, 19.11.2016 №21/42, 04.09.2017 № 13/60, 11.07.2018 №18/102, 19.03.2019 №07/130, 19.02.2020 №02/158, 12.08.2021 № 16/36, 06.07.2022 № 23/71 номерлы карарлар редакциясендә) үзгәрешләр кертү проектын әзерләргә керешергә

1.1. 25 статьяны «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 12 пунктына туры китерергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Урманай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш

кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru.//

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: Э.Р.Абдуллина

Азнакай муниципаль районы Урманай авыл
җирлеге башкарма комитет карарына
1 нче кушымта
№ 18 19.10.2022 ел

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урманай авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында муниципаль берәмлек проектын әзерләү эшләрен башкаруның якынча сроклары**

| N | «Урманай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен уздыру тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2022 елның IV кварталы |
| 2.<br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең шәһәр төзелеше регламентларына үзгәрешләр кертү, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләрнең һәм ведомстволарның искәрмәләренә шәрехләр әзерләү. | 2022 елның IV кварталы |
| 3.<br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышу.<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башлыгына Азнакай муниципаль районының «Урманай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектын һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарны (ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) авыл җирлеге Советына раслау яисә кире кагу өчен җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын җибәрү турында карар кабул итү өчен, аны кабат тәкъдим итү көнен күрсәтеп, эшләп бетерерү турында карар кабул итү өчен юлларга. | 2022 елның IV кварталы |